РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 18

2020 елның 21 феврале

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2012 елның 20 декабрендә кабул ителгән 68 номерлы «Түбән Кама муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең коррупцион хокук бозулар кылган өчен җаваплылыгы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» Законы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советының «Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен Түбән Кама муниципаль районы Советына тапшыру турында килешүләрне раслау турында» 2018 елның 17 маендагы 37 номерлы карарына таянып, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2012 елның 20 декабрендәге 68 номерлы карары белән расланган коррупцион хокук бозулар кылган өчен (алга таба текст буенча - Нигезләмә) Түбән Кама муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Нигезләмәнең преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә карата, шулай ук Түбән Кама муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренең муниципаль хезмәткәрләренә карата, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешендә билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәт өлкәсендә муниципаль хокукый актлар кабул итү буенча вәкаләтләр әлеге җирлекләр тарафыннан тапшырылган очракта, җәзалар һәм башка җаваплылык чараларын куллану тәртибе билгеләнә (алга таба – муниципаль хезмәткәрләр).»;

б) «1.3. Дисциплинар җәзаларны куллану һәм юкка чыгару тәртибе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.»;

в) 1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «1.4. Дисциплинар җәза яллаучы (эш бирүче) вәкиле боерыгы белән салына.»;

г) 1.8 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

д) 1.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «1.9. Әлеге Нигезләмәнең 1.1. пунктында каралган җәзалар муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коррупцион хокук бозу кылу турында мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча эшкә сәләтсезлек, отпускта булу чорларын санамыйча һәм коррупцион хокук бозу кылган көннән өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән вакытка җинаять эше буенча алып барылган эш вакыты кертелми.»;

е) 2.5 пунктында:

1) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «- җирле үзидарә органнарының кадрлар хезмәте бүлекчәләре тарафыннан коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад;»

2) түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац өстәргә: «-аны кылуның факттагы шартлары бәян ителә, һәм муниципаль хезмәткәрнең бары тик аның ризалыгы белән һәм коррупцион хокук бозу фактын тану шарты белән аларга язма аңлатма бирү бәян ителгән (ышаныч югалтуга бәйле рәвештә, эштән азат итү рәвешендәге җәзаны куллanудан тыш) коррупцион хокук бозу кылу турында җирле үзидарә органының коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе нотыгы;»;

ж) 3.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «3.3. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан билгеләнә торган башка җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә карата аларны дисциплинар җаваплылыкка тарту мәсьәләсе Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан үз инициативасы яисә Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы инициативасы белән кабул ителә.»;

з) 4.3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирле үзидарә, регламент һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы

ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН

А.Р.Метшин